**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«18» ноябрь 2020 ел** **№ 292**

2021 елга Азнакай муниципаль районы туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле оешмаларның норматив чыгымнары турында

2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 99 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 30 декабрендәге 939 номерлы «Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен туристик-крайны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф учреждениеләрен һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары һәм Татарстан Республикасының «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы белән, карар итә:

1. Расларга:

- кушымта нигезендә, Азнакай муниципаль районы балаларына өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында туристик-туган якны өйрәнү, экологик-биологик, хәрби-патриотик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле мәгариф учреждениеләрен һәм өстәмә белем бирүнең күппрофильле мәгариф учреждениеләрен гамәлгә ашыруга беркетелгән норматив кушымта итеп бирелә торган чыгымнарны.

- балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм

культурология юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү күппрофильле мәгариф оешмаларында 0,5 күләмендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициентын.

2. «Азнакай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә тәэмин итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны.

- әлеге карарның 1 пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булган чор дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бергә, яңадан карау.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет - телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм финанслар буенча урынбасары О.Н. Газизовага йөкләргә.

Җитәкче                                        А. Х. Шәмсетдинов

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карарына кушымта
«______»____________2020 №______

**Туристлык-туган якны өйрәнү, экология-иология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Юнәлеш | Территориаль урнашу | Беренче уку елында 1 укучыга бер елга норматив чыгымнар, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетик | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туризм-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисади | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |